| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Заречный пос. | **КАРАР** |
| «03» декабрь 2025 ел | | № 7 |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану, элек расланган карарларга үзгәрешләр, өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 13 декабрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлегендә Центральная урамы 4 адресы буенча урнашкан авыл клубы янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Элек расланган карарларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннары:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге составына керүче заречный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 27.11.2025 ел, №7 карар;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Зареченский авыл җирлегенең Заречный торак пунктында гражданнар Җыенының 27.11.2025 ел, № 8 карары.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный поселогы гражданнары җыенын үткәрү һәм оештыруны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм Заречный авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

4.1«Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларның толларыннан тыш балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4.2. «2023 елда калган республика акчаларын 175580,00 (йөз җитмеш биш мең биш йөз сиксән сум 00 тиен) балалар мәйданчыгы сатып алуга, торак пункт территориясен төзекләндерүгә (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Зареченский авыл җирлегенең Заречный пос. торак пункты территориясен төзекләндерүгә) юнәлтергә ризамы?;

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова